ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«16» декабрь 2024 ел** **№ 1024**

**«Балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф учреждениеләренең һәм спорт мәктәпләренең матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» 2023 елның 02 октябрендәге 838 номерлы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы балаларының һәм халкының ялын оештыру өчен шартлар тудыру, өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту максатыннан, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

«Балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф учреждениеләренең һәм спорт мәктәпләренең матди-техник базасын үстерүгә һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» 2023 елның 02 октябрендәге 838 номерлы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Арча Арена» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең өстәмә белем бирү хезмәтләре дигән 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш. Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

Арча муниципаль районы

Башкарма комитетының
16.12.2024 ел, № 1024г
карарына кушымта

«Арча Арена» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе

| № | **Хезмәтнең аталышы** | **Халык категориясе** | **Булу вакыты, сәг.** | **Бәясе, сум** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Тимераякларны прокатка бирү | Яшь буенча чикләүләрсез | 1 | 50 |
| 2 | Бозда шуу | Яшь буенча чикләүләрсез | 1 | 100 |
| 3 | Бозны прокатка бирү | Корпоратив шуу | 1 | 3000 |
| | | Читтән килүчеләр | 1 | 3500 |
| | | Арча шәһәре һәм районы халкы | 1 | 2000 |
| 4 | Тимеракларны үткенләү (1 пар) | Өлкәннәр | | 100 |
| | | Өлкәннәр (ярышлар вакытында) | | 150 |
| | | 16 яшькә кадәрге балалар | | 50 |
| 5 | Душ | | 30 мин. | 50 |
| 6 | Бозда шуганда өстәмә чишенү бүлмәсе бирү | Бозны арендага алучылар өчен | 1 | 700 |
| 7 | Хоккей матчын карау | | 1,5 | 30 |
| 8 | Хоккей турнирын карау | | 1 көн | 50 |